КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 18 март г.Казань № 186

Татарстан Республикасының Зеленодольск муниципаль районы территориясендә «Каракүл» табигать объектын төбәк әһәмиятендәге табигать ядкәре дип игълан итү турында

«Махсус саклана торган табигать территорияләре турында» 1995 ел, 14 март, ФЗ-33 нче һәм «Хайваннар дөньясы турында» 1995 ел, 24 апрель, ФЗ-52 нче федераль законнар, Россия Федерациясе Су кодексы һәм Татарстан Республикасы Экология Кодексы нигезендә, биология төрлелеген, шулай ук Зеленодольск муниципаль районында кыйммәтле табигать объектын саклап калу максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биология ресурслары буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә 2 гектар гомуми мәйданлы «Каракүл»[1] табигать объектын – «Каракүл» төбәк әһәмиятендәге табигать ядкәре, ә ул урнашкан территорияне төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территориясе дип игълан итү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. «Каракүл» төбәк әһәмиятендәге табигать ядкәре турындагы нигезләмәне һәм аның чиген (карарга теркәлә) расларга.

3. «Каракүл» төбәк әһәмиятендәге табигать ядкәре чикләре һәм аның махсус саклау режимы үзенчәлекләре икътисадый һәм социаль үсеш планнарын һәм перспективаларын эшләгәндә, территориаль планлаштыру документларын әзерләгәндә, җирләргә инвентаризация үткәргәндә исәпкә алына дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитетына:

Татарстан Республикасының махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрына тиешле үзгәрешләр кертү турындагы Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

«Каракүл» төбәк әһәмиятендәге табигать ядкәре чикләре турындагы мәгълүматларны «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына билгеләнгән тәртиптә кертүне тәэмин итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

---

[i] Тәрҗемәи сүзлекләрдә булмау сәбәпле, әлеге күлнең татар телендәге исеме тәрҗемәче тарафыннан тәкъдим ителә – А.М.Сәгыйтова искәрмәсе.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 18 март, 186 нчы
карары белән расланды

«Каракүл» төбәк әһәмиятендәге табигать ядкәре турында
нигезләмә

1. «Каракүл» төбәк әһәмиятендәге табигать ядкәре (алга таба – табигать ядкәре) уникаль күл комплексын саклап калу, Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән хайваннарның һәм үсемлекләрнең су һәм су янында яши һәм үсә торган төрләрен саклау максаты белән оештырылган төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территориясе булып тора.

2. Табигать ядкәре Татарстан Республикасының Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан һәм гомуми мәйданы 2 гектар тәшкил итә. Табигать ядкәре территориясен төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территориясе дип игълан итү бу участокларның милекчеләреннән, хуҗаларыннан һәм кулланучылардан алар биләгән җир кишәрлекләрен тартып алмыйча башкарыла.

3. Табигать ядкәре Татарстан Республикасының табигать-тыюлык фонды составына керә.

4. Табигать ядкәре Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты (алга таба – Комитет) карамагында була.

II. «Каракүл» төбәк әһәмиятендәге табигать ядкәре эшчәнлеген оештырганда Татарстан Республикасы Биология ресурслары буенча дәүләт комитетының төп бурычлары

5. Табигать ядкәренең төп бурычлары:

уникаль күл комплексын саклап калу;

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән хайваннарның һәм үсемлекләрнең су һәм су янында яши һәм үсә торган төрләрен саклау.

III. . «Каракүл» төбәк әһәмиятендәге табигать ядкәренең урнашу урыны

6. Табигать ядкәре Татарстан Республикасының Зеленодольск муниципаль районы территориясендә, Ивановский поселогыннан 500 метр төньяк-көнбатышта урнашкан.

7. Табигать ядкәренең чикләре җирлектә саклау режимы һәм аның чикләр схемасы кыскача бәян ителә торган махсус мәгълүмати билгеләр белән билгеләнә.

## IV. «Каракүл» төбәк әһәмиятендәге табигать ядкәрен махсус саклау режимы

8. Табигать ядкәре территориясендә Табигать ядкәренең сакланышын боза торган теләсә нинди эшчәнлек, шул исәптән түбәндәгеләр тыела:

кискен тирбәлешләрне барлыкка китерә торган шартлаткыч чыганаклары белән геология разведкасы һәм сейсмик разведка эшләрен үткәрү;

аулау (фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм санны җайга салу максатларында аулаудан тыш);

аучылык һәм балыкчылык объектларына кертелмәгән хайваннарны аулау, шулай ук Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән хайваннарның, үсемлекләрнең һәм гөмбәләрнең сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган төрләрен аулау һәм җыю;

ояларны, өннәрне, башка качу урыннарын юкка чыгару, шулай ук кыргый хайваннарны борчуга китерә торган гамәлләр;

агу химикатларын, минераль ашламалар, үсемлекләрне саклый торган химик чаралар куллану һәм үстерү стимуляторларын куллану;

су объекты ярларында автотранспорт чараларын һәм авыл хуҗалыгы техникасын юу;

агып төшерелә торган суларны һәм (яки) дренаж суларын агызу;

бу территориянең экологик кыйммәтен киметүгә яки сакланыла торган хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы объектларына һәм аларның яшәү мохитенә зыян сала торган, табигать комплексының экологик тигезлеген бозуга китерә торган эшчәнлекнең башка төрләре.

9. Табигать ядкәре территориясендә түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

законнар нигезендә һәвәскәр һәм спорт балыкчылыгы;

фәнни тикшеренүләр, шул исәптән экологик мониторинг максатларында фәнни тикшеренүләр үткәрү;

экологик агарту чараларын оештыру (укыту-танып белү экскурсияләрен үткәрү, экологик укыту һәм экскурсия сукмакларын оештыру һәм төзекләндерү, экологик туризмны үстерү);

хайваннар дөньясы объектлары санын җайга салу буенча чаралар;

Табигать ядкәрен саклау максатларына каршы килми торган, су хайваннарына һәм су янында яши торган хайваннарга зыян салмый торган һәм бу табигать комплексның экологик тасвирнамәләрен сакларга мөмкинлек бирә торган башка эшчәнлек.


10. Табигать ядкәре территориясендә рөхсәт ителгән хуҗалык эшчәнлеге Табигать ядкәренең билгеләнгән махсус саклау режимы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җитештерү процессларын башкарганда, шулай ук транспорт магистральләрен, үткәргеч торбаларны, элемтә һәм электр тапшыру линияләрен эксплуатацияләгәндә хайваннар дөньясы объектлары һәлак булуга юл куймауга карата таләпләрне раслау турында» 1996 ел, 13 август, 997 нче карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

11. Табигать ядкәре чикләрендә төзергә, реконструкцияләргә планлаштырыла торган объектларның проект документларына, шулай ук Табигать ядкәре чикләрендә төзергә, реконструкцияләргә планлаштырыла торган аеруча куркыныч, техник яктан катлаулы һәм уникаль объектларның, оборона һәм куркынычсызлык объектларының проект документларына, әгәр дә мондый объектларны махсус саклана торган табигать территорияләре чикләрендә төзү, реконструкцияләү Россия Федерациясе законнары белән рөхсәт ителсә, дәүләт экология экспертизасы үткәрелергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 18 март, 186 нчы
карары белән расланды

**«Каракүл»**
**төбәк әһәмиятендәге табигать ядкәре чикләре**


«Каракүл» төбәк әһәмиятендәге табигать ядкәре карта-схемасы




Шартлы билгеләмәләр:

– «Каракүл» төбәк әһәмиятендәге табигать ядкәре чиге.

«Каракүл» төбәк әһәмиятендәге табигать ядкәре
урнашу урынының график тасвирламасы




«Каракүл» төбәк әһәмиятендәге табигать ядкәре чикләренең
характерлы нокталары координатлары исемлеге

| Нокта саннары | География координатлары |
|---|---|
| 1 | 55.965751 N, 48.840456 E |
| 2 | 55.966150 N, 48.840869 E |
| 3 | 55.966177 N, 48.841958 E |
| 4 | 55.966120 N, 48.842355 E |
| 5 | 55.965835 N, 48.842639 E |
| 6 | 55.965360 N, 48.843020 E |
| 7 | 55.965190 N, 48.842991 E |
| 8 | 55.965153 N, 48.842768 E |
| 9 | 55.965021 N, 48.842736 E |
| 10 | 55.964709 N, 48.843475 E |
| 11 | 55.964469 N, 48.843487 E |
| 12 | 55.964360 N, 48.843057 E |
| 13 | 55.964678 N, 48.841939 E |
| 14 | 55.965316 N, 48.840932 E |